**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2274**
**29.04.2022**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2018 елның 23 гыйнварындагы 251 номерлы, 2021 елның 26 мартындагы 2090 номерлы, 2021 елның 23 июлендәге 4940 номерлы карарлары редакциясендә), 4 нче кушымтаның 3 пунктындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Кп – сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы кафелар өчен кулланыла торган коэффициент – 80, консервация чорына стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы кафелар өчен – 0, 2022 елның 1 маеннан 2023 елның 30 апреленә кадәр урнаштыру хокукына шартнамәләрнең гамәлдә булу чорына стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы кафелар өчен – 0;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов